# ФӘНИС ЯРУЛЛИН ЯЗМЫШЫНА ДУЧАР ШӘХЕСЛӘР

Өченче санлы Урыссу урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гарипова Зөлфирә Хөсәен кызының регионара семинарда ясаган чыгышына презентация

# Шагыйрь Гакыйль Сәгыйров



Ул тумыштан гарип. Ләкин аның яшәүгә, иҗатка омтылышы шулкадәр көчле ки, ул аяк бармаклары арасына каләмен кыстырып шигырьләр яза. Ә карандаш белән

# Язучы Фатих Әмирхан



21 яшендә аны паралич суга, аяк-куллары йөрми, күзләре начарлана. Ләкин бу фаҗига аның ихтыяр көчен, рухын һәм холкын сындырмый. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул оптимист, тормыш сөючән, тапкыр сүзле, сәламәт акыллы булып кала.

# Рәссам Герман Соколов



Ул да фаҗигале язмыш иясе. Аның яраткан темасы – пейзаж. Автор рәсемнәрне пумаланы үзенең чак кына кыймылдый алган сул аягының бармакларына кыстырып ясый.

# Шагыйрә Антонина Баева



Хезмәт юлын укытучы булып башлаган, ләкин каты авырудан соң аяктан егылып, озак еллар гомерен урын өстендә үткәрүче шагыйрә үзендә яшәүгә һәм иҗатка рухи көч таба.

# Язучы Владислав Титов



“Всем смертям назло...” повесте – автобиографик әсәр. Анда типсә тимер өзәрлек егетнең, эштә югары көчәнешле электр тогына эләгеп, ике кулсыз калуы һәм шуннан соң яшәү өчен көрәше гәүдәләнә.

# Язучы Николай Островский



Бу әдипнең “Корыч ничек чыныкты?” романы, мөгаен, Фәнис Яруллинның гына түгел, ә югарыда әйтеп үтелгән иптәшләренең барысы өчен дә өстәл китабы булгандыр, аларга